ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 15 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 659**

«Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 10 октябрендәге 785 номерлы
карары белән расланган,
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясеннән авиация эшләре, парашют сикерүләре, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратлары, бәйле аэростатларны күтәрү, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданнарга утырту (очып китү), аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган мәйданчыкларга рөхсәтләр бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында»

Норматив хокукый актны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 3 февралендәге 74 номерлы карарына таянып, норматив хокукый актны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 октябрендәге 785 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясеннән авиация эшләре, парашют сикерүләре, һава судноларының демонстрацион очышлары, пилотсыз очу аппаратлары, бәйле аэростатларны күтәрү, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданнарга утырту (очып китү), аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган мәйданчыкларга рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

исемендә һәм бөтен текст буенча:

- «пилотсыз очу аппаратларының очышлары» сүзләрен «пилотсыз һава судноларының очулары (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан да ким булган пилотсыз һава судноларының очуларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов